КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 12 декабрь

г.Казань

№ 1308

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә суыткычлар, туңдыргычлар, медицина суыткыч җиһазы җитештерүче оборона-сәнәгать комплексы оешмаларына әлеге гражданнар билгеләнешендәге продукцияне җитештерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 24 ноябрь, 1116 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә суыткычлар, туңдыргычлар, медицина суыткыч җиһазы җитештерүче оборона-сәнәгать комплексы оешмаларына әлеге гражданнар билгеләнешендәге продукцияне җитештерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә суыткычлар, туңдыргычлар, медицина суыткыч җиһазы җитештерүче оборона-сәнәгать комплексы оешмаларына әлеге гражданнар билгеләнешендәге продукцияне җитештерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау

максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 24 ноябрь, 1116 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 22 сентябрь, 1030 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә суыткычлар, туңдыргычлар, медицина суыткыч җиһазы җитештерүче оборона-сәнәгать комплексы оешмаларына әлеге гражданнар билгеләнешендәге продукцияне җитештерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидияләр турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

4 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 нчы календарь көннән иртәрәк була алмый);»;

16 пунктның өченче абзацында «субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләре» сүзләрен «субсидия бирү төгәлләнә торган төгәл дата һәм аны бирү нәтиҗәсенең соңгы күрсәткече (йомгакларның төгәл микъдари тасвирнамәсе)» сүзләренә алмаштырырга».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин